Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLIII-12**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 26 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә үзидарәлек һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары контроле төрләренең исемлеген алып бару тәртибе турында

2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм үзидарәлек контролен гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар хокукларын яклау турында” 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 маддәсе 2 өлешенең 1 пункты, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә үзидарәлек һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары контроле төрләренең исемлеген алып бару тәртибен расларга (теркәлә).

2. Әлеге карар нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә үзидарәлек һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары контроле төрләренең исемлеген төзүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2019 елның 26 июнендәге
XLIII-12 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә үзидарәлек һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары контроле төрләренең исемлеген алып бару**
**Тәртибе**

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә үзидарәлек һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары контроле төрләренең исемлеген алып бару кагыйдәләрен тәгаенли.

2. Үзидарәлек һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары контроле төрләренең исемлеге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана. Контроль төрләренең исемлеге үзидарәлек контролен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары тапшырган мәгълүматлар нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге тарафыннан төзелә (формалаштырыла) һәм алып барыла.

3. Контроль төрләренең исемлеге түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

1) Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган үзидарәлек контроле төренең исеме;

2) Балык Бистәсе муниципаль районының үзидарәлек контроленең тиңдәшле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән җирле үзидарә органнары исеме, аларның урнашу урыны, телефоны;

3) үзидарәлек контролен гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының норматив хокукый актының, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының үзидарәлек норматив хокукый актының исеме һәм реквизитлары;

4.Контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертелә:

1)үзидарәлек контроленең яңа төрен кертү яки үзидарәлек контроле төрен төшереп калдыру зарурлыгы туган очракта;

2) үзидарәлек контролен гамәлгә ашыруны тәртипкә салучы норматив хокукый актларның реквизитларын анıклау максатларында;

3) үзидарәлек контролен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органының исеме үзгәрү белән бәйле рәвештә.

5. Үзидарәлек контролен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына үзидарәлек контролен гамәлгә ашыруны тәртипкә салучы һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларга үзгәрешләр кертүче норматив хокукый актның үз көченә керү көненнән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тәкъдим юллый.

Үзидарәлек контролен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы бетерелгән очракта контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимне кыскартылган җирле үзидарә органы вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органы юллый.

6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимне карый һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда тәкъдим Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына кергән көннән соң 10 көннән артмаган срокта контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләрне кертә.

7. Контроль төрләре исемлегенә кертелгән мәгълүмат һәркем өчен керү мөмкинлегенә ия. Контроль төрләре исемлеге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.